| ГЛАВА<br>БУТЛЕРОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БУТЛЕРОВКА АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.10.2019 №8

с.Мокрые Курнали

**Алексеевского муниципаль районының
"Бутлеровка җирлеге территориясендәге
Бутлеровка авылында үзара салым кертү
һәм гражданнарның үзара салым
акчаларыннан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында "**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ" Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы» , Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә,

**Карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районының Бутлеровка җирлеге территориясендәге Бутлеровка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча 2019 елның 13 нче ноябре көнне 13сәг 00 минутта гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:
Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка җирлеге территориясендәге Бутлеровка авылында 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә,үзара салымны ,барлык шул җирлек территориясендә теркәлгән,балигъ булган затлардан, хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар ,1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку бүлеге студентларыннан тыш, җыюга һәм акчаларны җирле түбәндәге мәсәләләрне хәл итүгә тотуга сез ризамы?

- вак таш җәю, төзекләндерү һәм юлларны карап тоту;
- урамнарны төзекләндерү

" ӘЙЕ " КАРШЫ"

3.Халык җыенын оештыручы итеп Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4.Җыенның үткәрү урыны дип авыл мәдәният йортын билгеләргә.Адресы: Татарстан Республикасы.Алексеевск районы, Бутлеровка авылы, Центральный урамы 38 йорт.

5.Әлеге карарны Бутлеровка авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

6. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Бутлеровка авыл җирлеге башлыгы**
**Совет Рәисе** **Ф.А.Хайрутдинова**

СОВЕТ БУТЛЕРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ